**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14.11.2024 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кичкетаң торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 ноябрендә 14:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

а) Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау *(электр товарлары сатып алу һәм лампаларны, фонарьларны алмаштыру, хезмәт шартнамәсе буенча хезмәт өчен түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар).*

б) Торак пункт территориясен төзекләндерү (*үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактор өчен өстәмә асылма җайланмалар сатып алу, «Изге Чишмә» чишмәсе территориясен төзекләндерү торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар*).

в) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (*ягулык-майлау материаллары, янгын машинасы өчен запас частьләр сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар*).

г) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (*рөхсәтсез чүплекләрне бетерү*).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 335 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 180 кеше, бу 53,73% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 180 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кичкетаң торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кичкетаң торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналарыннан, хатыннарыннан, балигъ булмаган балаларыннан) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (*лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар)*;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (*үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактор өчен өстәмә асылма җайланмалар сатып алу, «Изге Чишмә» чишмәсе территориясен төзекләндерү торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар*);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (*ягулык-майлау материаллары, янгын машинасы өчен запас частьләр сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар)*;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (*рөхсәтсез чүплекләрне бетерү*).

4. Мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыены рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы

Совет Кичкетанского сельского поселения
Кичкетан авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002452

И.Н.Җиһангәрәев